ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ		ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

ПРИКАЗ **БОЕРЫК**

27.07.2020 Казан шәһәре № 82

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 16 маендагы 50 номерлы боерыгы белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 16 маендагы 395 номерлы һәм «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 12 июнендәге 482 номерлы карарлары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының «Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый

файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 16 маендагы 50 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2019 елның 23 декабрендәге 227 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Е.А.Барабановага йөкләргә.

Рәис С.Е. Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2019 елның
16 маендагы 50 номерлы
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2020 елның
27 июлендәге 82 номерлы
боерыгы редакциясендә)

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) тәртибен һәм стандартын билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: «Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 2^2 пунктының 1 пунктчасында каралган социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар (алга таба – социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар, коммерциясез оешмалар) (әлеге абзац таләбе 2020 елның 15 сентябреннән гамәлдә була).

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Дәүләт комитетының урнашу урыны: Казан шәһәре, Максим Горький урамы, 19.

Дәүләт комитетының эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, җомга: 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы: Дәүләт комитетының эше сәгатьләрендә, шимбә, якшәмбедән тыш, көн саен.

Җәмәгать транспортында «Гоголь урамы» тукталышына кадәр килергә.

10, 10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 35а, 54, 63, 83, 89, 91, 98 номерлы автобуслар;

2, 3, 5, 7, 8 номерлы троллейбуслар;

«Тукай мәйданы» метро станциясе.

Кертү пропуск һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ ярдәмендә.

1.3.2. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының туристлык индустриясен үстерү бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 222-90-40, 222-90-20.

1.3.3. Дәүләт комитетының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://tourism.tatarstan.ru/, электрон почта адресы: tourism.rt@tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, Дәүләт комитетының мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мәгълүмат стендлары аша;

2) «Интернет» челтәре аша:

Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru);

3) Дәүләт комитетына телдән (шәхсән яисә телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә;

4) Дәүләт комитетына язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Дәүләт комитеты урнашкан урын, аның белешмә телефоннары, эш графигы, шулай ук Дәүләт комитетының электрон почта адресы турында мәгълүмат Бүлек җитәкчесе тарафыннан Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

1.3.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат стендларында һәм Дәүләт комитетының рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларның рәсми басылып чыгу чыганакларын да күрсәтеп) Дәүләт комитетының рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү – экскурсия хезмәте күрсәтү; экскурсия программалары оештыру; туристлык буенча мәгълүмат хезмәтләре күрсәтү;

мөрәҗәгать итүче – дәүләт хезмәте күрсәтү турында телдән, язмача яки электрон формада чагылдырылган рәсми мөрәҗәгать белән мөрәҗәгать итүче социаль юнәлешле коммерциясез оешма (аның вәкаләтле вәкилләре);

техник хата – Дәүләт комитеты җибәргән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган

документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу хатасы, басма хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәре яки муниципаль районы яки шәһәр (авыл) җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (алга таба – рәсми мөрәҗәгать) – 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза. Рәсми мөрҗәгатьнең киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы	Стандартка карата таләпләр эчтәлеге	Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт
2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы	Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү	Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру хакында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру хакындагы нигезләмәнең (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмә) 2 пункты

2.2. Башкарма хакимият органы исеме	Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүче-коммерциясез оешмалар реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүче дип тану турында карар кабул итү кагыйдәләренең (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр) 2 пункты; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 2 пункты; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 елның 12 апрелендәге 234 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәнең 4.1 пункты
2.3. Дәүләт хезмәте	Социаль юнәлешле коммерциясез оешма	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017

күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама	тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының экскурсия хезмәте күрсәтү, экскурсия программалары оештыру, туристлык буенча мәгълүмат хезмәтләре күрсәтү өлкәсендә билгеләнгән критерийларга туры килүе турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган кагыйдәләргә 2 нче кушымтага ярашлы форма буенча бәяләмә бирү яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына туры китерелгән формада нигезле хәбәр җибәрү	елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 5, 8 пунктлары
2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган	Бәяләмә бирү турында рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап 30 көн эчендә. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Дәүләт комитеты тарафыннан рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрелгән очракта, әлеге вакыт арттырылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел. Әлеге карарны кабул итү вакытын арттыру турында Дәүләт комитеты мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү турында оешмадан рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап 30 көн эчендә хәбәр итә. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче килгән көнне бирелә. Рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулыннан	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 9 пункты

документларны бирү (җибәрү) вакыты	(почта буенча, электрон адреска, факс аша) файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштергән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.	
2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе	а) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (алга таба – рәсми мөрәҗәгать); б) гамәлгә кую документларының күчермәләре; в) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклый торган, мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртү өчен кирәкле ышаныч кәгазе, – документлар мөрәҗәгать итүченең вәкиле аша тапшырылган очракта. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан оешма күрсәтә торган хезмәтнең иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган документлар (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һәм башкалар) теркәлергә мөмкин. Әгәр мөрәҗәгать итүче тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт төре буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүче затлар реестрына кертелгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр сыйфатының иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерийларга туры килүен нигезли торган өстәмә документларны тапшыру таләп ителми	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 5 пункты

2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарына һәм җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә дә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма	Мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тапшырыла торган айның беренче көненә салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарны, җыемнарны, иминият кертемнәрен, пеняларны, штрафларны, процентларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең булмавын, оешманың намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавын раслый торган документлар. Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый. Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела: дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүмат тапшыруны яки гамәлләр башкаруны; 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 6 пункты; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары)

	оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматларны тапшыруны, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәткән өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан түләү кертелүен раслый торганнарын да; дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны	
2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге	Мөрәҗәгать итүче яки аның вәкиле тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында саналган документлар тапшырылмаганда	
2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге	Бәяләмә бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора: а) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве; б) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы	Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 7 пункты

	килешүләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән һөнәри белеменең, тиешле өлкәдәге эш тәҗрибәсенең) булмавы; в) бәяләмә бирелә торган елга кадәрге ике ел эчендә оешманың ул күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәткә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм, компетенцияләренә туры китереп, башка дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләр булуы; г) оешма турында мәгълүматның ачык һәм үтемле булу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый акларында билгеләнгән таләпләргә (булган очракта) туры килмәве; д) бәяләмә бирелгән елдан алдагы ике ел эчендә «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы; е) салымнар һәм җыемнар буенча, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәҗбүри түләүләр буенча әҗәтләр булуы; ж) төгәл булмаган белешмәләре булган документларны яки тиешле тәртиптә рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыруы.	

	Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату өчен нигезләр юк	
2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре	Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә	
2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турындагы белешмәләр	Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми	
2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау	Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми	

методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп		
2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры	Мөрәҗәгать итүчене кабул итүне (аңа хезмәт күрсәтелүне) көтү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.	Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указының 1 пунктындагы «д» пунктчасы
2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең рәсми мөрәҗәгатен теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада да	Рәсми мөрәҗәгать алынган көнне. Рәсми мөрәҗәгать электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә	

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул исәптән әлеге объектларның инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр	Дәүләт хезмәте янгын сүндерүнең янгынга каршы системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән бинада һәм бүлмәдә күрсәтелә. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урыннарга инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу (бүлмәләргә уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү) мөмкинлеге тудырыла. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шулай ук инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.	«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карары

2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп хезмәттәшлек итү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып та, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм	Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу күрсәткечләре: документларны кабул итү һәм тапшыру эшләре башкарыла торган биналарның җәмәгать транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы; белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннарның кирәкле санда булуы; мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Дәүләт комитетының рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы; дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуы; инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы; дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чорының саклануы; Дәүләт комитеты белгечләре тарафыннан Регламент бозылуга бәйле прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы; мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгечләре	

муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән һәм (яки) муниципаль хезмәттән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган рәсми мөрәҗәгатьне тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалана алу мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау	белән бәйләнешкә керү күләме; дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле рәсми мөрәҗәгатьне һәм документларны тапшырганда һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда, турыдан-туры – ике мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча); дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча). Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитеты белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 15 минуттан артмый. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча рәсми мөрәҗәгать тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Дәүләт комитетының http://tourism.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан алынырга мөмкин. Экстерриториаль принцип һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтелми.	
2.16. Дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен, шул исәптән	Рәсми мөрәҗәгать һәм документлар (документларның күчермәләре) Дәүләт комитетына «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге	

экстерриториаль принцип буенча да (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта), һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган башка таләпләр	63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә квалификацияле электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.	

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

3.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү һәм аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә;

2) рәсми мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты әзерләү;

5) мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү бирү;

6) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультация алу өчен Бүлеккә шәхсән, телефон аша һәм (яки) почта ярдәмендә (шул исәптән электрон) мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Бүлек җитәкчесе мөрәҗәгать итүчене консультацияли, шул исәптән рәсми мөрәҗәгатьнең формасы һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча да. Кирәк булганда, Бүлек җитәкчесе мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә дә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләрдә консультацияләү, шулай ук күрсәтелгән ярдәм.

3.3. Рәсми мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) Дәүләт комитетының кадрлар бүлеге һәм юридик эш бүлегенең Дәүләт комитетында эшчәнлек алып баруга җаваплы белгеченә (алга таба – Эшчәнлек алып баручы зат) рәсми мөрәҗәгатьне шәхсән тапшыра.

Рәсми мөрәҗәгать почта аша заказлы юллама итеп җибәрелергә мөмкин.

Рәсми мөрәҗәгать шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да бирелергә мөмкин.

Рәсми мөрәҗәгатьне электрон формада җибәргән очракта, соралган документларның сканер аша чыгарылган күчермәләре теркәлә, рәсми мөрәҗәгать почтадан җибәрелгәндә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан таныкланган документлар теркәлә.

3.3.2. Эшчәнлек алып баручы зат:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле буларак катнашучы затның яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирү-бирмәвен тикшерә. Тикшерү Бүлек җитәкчесе катнашында гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, документларны кабул итүдән әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган баш тарту нигезләре булган очракта, Эшчәнлек алып баручы зат мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм рәсми мөрәҗәгатьне теркәүдән баш тарту нигезләре булуы турында хәбәр итә һәм аңа, баш тарту өчен ачыкланган нигезләр эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтарып бирә. Мөрәҗәгать итүченең таләбе буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче рәсми мөрәҗәгатьне һәм документларны почта аша (электрон почтадан) җибәргән очракта, Эшчәнлек алып баручы зат, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны аңа почта аша (электрон почтадан) җибәрә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаган очракта, Эшчәнлек алып баручы зат:

рәсми мөрәҗәгатьне кабул итә һәм терки;

документларны кабул итү датасы һәм вакыты, кергәндә беркетелгән номеры турында тамгалап, рәсми мөрәҗәгать күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә тапшыра яки почта буенча яки электрон почта (аның ихтыярына карап) аша җибәрә;

рәсми мөрәҗәгатьне электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасы (алга таба – электрон документ әйләнеше) аша Дәүләт комитеты рәисенә (алга таба – Рәис) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсми мөрәҗәгать килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Рәискә җибәрелгән рәсми мөрәҗәгать.

3.3.3. Рәис рәсми мөрәҗәгатьне карый һәм карап тикшерү өчен Дәүләт комитеты рәисе урынбасарына (алга таба – Рәис урынбасары) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсми мөрәҗәгать теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен Дәүләт комитеты рәисе урынбасарына җибәрелгән рәсми мөрәҗәгать.

3.3.4. Дәүләт комитеты рәисе урынбасары рәсми мөрәҗәгатьне карый һәм үтәү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсми мөрәҗәгать теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үтәү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.4. Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү.

3.4.1. Бүлек җитәкчесе рәсми мөрәҗәгатьне карый һәм, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, тиешле документларны (белешмәләрне) тапшыру турында көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыра һәм ведомствоара электрон багланышлар системасы каналлары буенча җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамлангач бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара электрон багланышлар системасы каналлары буенча җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Белешмәләр белән тәэмин итүче белгечләр ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә соралган документларны (белешмәләрне) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураларның нәтиҗәсе: рәсми мөрәҗәгатьләргә Дәүләт комитетына җибәрелгән җаваплар яки белешмәләрне бирүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Бәяләмә бирү турында карар әзерләү һәм кабул итү яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү әзерләү.

3.5.1. Бүлек җитәкчесе рәсми мөрәҗәгатьләргә килгән җаваплар нигезендә карар кабул итә һәм теркәлә торган хат, бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты әзерли һәм килештерү өчен Дәүләт комитеты рәисе урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган вакыттан башлап биш эш көне эчендә, ләкин бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү тапшыруның әлеге Регламентта билгеләнгән вакыты узганчыга кадәр кимендә ун көн алдан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Дәүләт комитеты рәисе урынбасарына җибәрелгән теркәлә торган хат, бәяләмә проекты яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

3.5.2. Дәүләт комитеты рәисе урынбасары теркәлә торган хатны, бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерә һәм Рәискә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге документлар килештерү өчен килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм карап тикшерү өчен Рәискә җибәрелгән теркәлә торган хат, бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

3.5.3. Рәис теркәлә торган хатны имзалый, бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерә.

Теркәлә торган хат, килештерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты, имзаланганнан соң, Эшчәнлек алып баручы затка җибәрелә.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшырылган, Рәис тарафыннан имзаланган теркәлә торган хат, килештерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

3.5.4. Эшчәнлек алып баручы зат:

теркәлә торган хатны терки һәм бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Процедураларның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән теркәлә торган хат, килештерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

Әлеге Регламентның 3.5.3-3.5.4 пунктчаларында билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.5.2 пунктчасында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

3.5.5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләрен алып баручы урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне алганнан соң, Бүлек җитәкчесе теркәлә торган хат проектын әзерли, аны Дәүләт комитеты рәисе урынбасары белән килештерә һәм имзалау өчен Рәискә җибәрә. Рәис теркәлә торган хатны имзалый һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләрен алып баручы урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү алынганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Рәис тарафыннан имзаланган, Бүлеккә җибәрелгән теркәлә торган хат.

3.5.6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан бәяләмә яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү алынганнан соң, Бүлек җитәкчесе теркәлә торган хат проекты әзерли, аны Дәүләт комитеты рәисе урынбасары белән килештерә һәм имзалау өчен Рәискә җибәрә. Рәис теркәлә торган хатны имзалый һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләрен алып баручы урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү алынганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Рәис тарафыннан имзаланган, Бүлеккә җибәрелгән теркәлә торган хат.

3.5.7. Бүлек җитәкчесе, рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр

итә, бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлә торган хатны Эшчәнлек алып баручы затка теркәү өчен тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар теркәлә торган хат Рәис тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшырылган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлә торган хат.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен юллау.

3.6.1. Эшчәнлек алып баручы зат бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлә торган хатны терки һәм аны рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (тапшыра).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Рәис тарафыннан теркәлә торган хат имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (тапшырылган) теркәлә торган хат.

3.7. Татарстан Республикасы Хөкүмәте рәсми порталының Интернет-кабул итү системасы аша алынган рәсми мөрәҗәгатьне карау.

Интернет-кабул итү системасы аша килгән рәсми мөрәҗәгать әлеге Регламентның 3.3-3.7 пунктчаларында каралган тәртиптә теркәлә һәм карала.

3.8. Техник хаталарны төзәтү.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүдә җибәрелгән техник хаталарны (язу хатасын, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне үзгәртеп рәсмиләштерү ирекле формада төзелгән, теркәлгән мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) нигезендә гамәлгә ашырыла, ул әлеге Регламентның 3.3.1 пункт-часында күрсәтелгән ысулларның берсе буенча тапшырыла. Мөрәҗәгатькә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак мөрәҗәгать итүчегә бирелгән, техник хатасы булган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү, шулай ук, документлар мөрәҗәгать итүче вәкиле тарафыннан тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче вәкиленең мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итү өчен кирәкле вәкаләтләрен таныклый торган ышаныч кәгазе теркәлә.

3.8.1. Эшчәнлек алып баручы зат:

техник хатаны төзәтү турындагы мөрәҗәгатьне кабул итә һәм электрон документ әйләнеше системасында терки;

электрон документ әйләнеше системасы аша мөрәҗәгатьне электрон рәвештә Рәискә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Рәискә җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.8.2. Рәис мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен Рәис урынбасарына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карау өчен Рәис урынбасарына җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.8.3. Рәис урынбасары мөрәҗәгатьне карый һәм үтәү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать теркәлгән көннән башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үтәү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.8.4. Бүлек җитәкчесе:

теркәлә торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты әзерли;

теркәлә торган хатны, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерү өчен Рәис урынбасарына юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать үтәү өчен Бүлек җитәкчесенә җибәрелгән көннән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: килештерү өчен Дәүләт комитеты рәисе урынбасарына җибәрелгән теркәлә торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

3.8.5. Рәис урынбасары теркәлә торган хатны, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерә һәм Дәүләт комитеты рәисенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура теркәлә торган хат, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү Бүлек җитәкчесеннән алынган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Рәис урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм карап тикшерү өчен Рәискә җибәрелгән теркәлә торган хат, бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

3.8.6. Рәис теркәлә торган хатны имзалый, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проектын яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проектын килештерә.

Имзаланганнан соң теркәлә торган хат, килештерелгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты Эшчәнлек алып баручы затка җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге проектлар килештерү өчен Рәискә килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшырылган, Рәис тарафыннан имзаланган теркәлә торган хат, килештерелгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү.

3.8.7. Эшчәнлек алып баручы зат теркәлә торган хатны терки һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты белән бергә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар теркәлә торган хат Рәис тарафыннан имзаланган һәм үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты килештелргән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән теркәлә торган хат, килештерелгән, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә проекты яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү проекты.

3.8.8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләрен алып баручы урынбасары тарафыннан имзаланган, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерүне алганнан соң, Бүлек җитәкчесе теркәлә торган хат проектын әзерли, аны Дәүләт комитеты рәисе урынбасары белән килештерә һәм имзалау өчен Рәискә җибәрә. Рәис теркәлә торган хатны имзалый һәм аны Бүлеккә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләрен алып баручы урынбасары тарафыннан имзаланган, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү алынганнан соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Рәис тарафыннан имзаланган, Бүлеккә җибәрелгән теркәлә торган хат.

3.8.9. Бүлек җитәкчесе, техник хатаны төзәтү турындагы мөрәҗәгатьтә яки дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, документның әзерлеге турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр җиткерә, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән берлектә теркәлә торган хатны, теркәү өчен, Эшчәнлек алып баручы затка тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар теркәлә торган хат Рәис тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәү өчен Эшчәнлек алып баручы затка тапшырылган, үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлә торган хат.

3.8.10. Эшчәнлек алып баручы зат үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлә торган хатны терки һәм аны рәсми мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә җибәрә (тапшыра).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар теркәлә торган хат Рәис тарафыннан имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү белән бергә теркәлгән, мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән (тапшырылган) теркәлә торган хат.

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвен һәм башкаруын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул ителүне тикшереп тору тиешле административ процедураны үтәү өчен җаваплы зат һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы булган Рәис урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Агымдагы контрольлек Дәүләт комитеты вазыйфаи затларының Регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольлек даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр үткәрүне, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына кагылышлы шикаятьләрне үз эченә алган мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүне, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен контрольлектә тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә карата тикшерүләр үткәрү тора:

эшчәнлекнең алып барылуына;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең законнардагы (Регламенттагы) таләпләргә туры килү-килмәвенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү сроклары һәм тәртибе үтәлешенә.

Тикшерүләр үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) юридик затлар Дәүләт комитетының дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавы) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.5. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүченең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.6. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Дәүләт комитеты эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәрге тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1^1 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары һәм дәүләт хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты яисә Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Дәүләт комитеты рәисенә шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә Рәис тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартылганда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты яисә Дәүләт комитеты дәүләт граждан хезмәткәре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда үзләре җибәргән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яки мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт комитеты, Дәүләт комитеты вазыйфаи заты, Дәүләт комитетының дәүләт хезмәткәре, Рәис карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша, Дәүләт комитетының рәсми сайтыннан (http://tourism.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең Дәүләт комитетының, аның вазыйфаи затының яки дәүләт граждан хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Шикаятьне карап тикшерү чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт комитетының, Дәүләт комитеты вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылганда, – теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.6 Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң бер көн узганчы мөрәҗәгать итүчегә язмача яисә, аның ихтыяры буенча, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезләнгән хат җибәрелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, Дәүләт комитетында гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

(формасы)

Кая ____
(дәүләт хезмәте күрсәтә
____
торган органның атамасы)
Кемнән _____________________________________
(фамилия, исем, ата исеме (булган очракта)/
____
мөрәҗәгать итүченең исеме) (гражданинның
____
шәхси иминият счеты номеры –
____
СНИЛС (физик затлар өчен))
____
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы (адреслары)
____
электрон почта – мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап)
____
(элемтә өчен телефон номеры (номерлары))

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать

____.
(дәүләт хезмәте атамасын күрсәтеп, рәсми мөрәҗәгать тексты)
____.
____.
____.

Кушымталар:
1. ____;
2. ____;
3. ____.

Шәхси белешмәләрне эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган режимда да, алар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү максатларында карарлар кабул итүне дә кертеп, (шәхси белешмәләрне җыюга, системага салуга, туплауга, саклауга, төгаенләүгә (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), шәхси үзенчәлекләрен бетерүгә, файдалана алмаслык итүгә, юкка чыгаруга, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү

кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле башка гамәлләргә) үз ризалыгымны, минем тарафтан вәкил булган затның риза булуы хакында раслыйм.

«___»________ 20__ел. ___________________________________ ___________________
(физик затның яки юридик зат вәкиленең имзасы) (Ф.И.А.)

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

(киңәш ителә торган рәвеше)

Социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле белдерү

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты тарафыннан уздырылган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча, социаль юнәлешле коммерциясез оешма:

____

____

(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы атамасы һәм төп дәүләт теркәвенә алу номеры)

тарафыннан күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының:

____

____

(иҗтимагый файдалы хезмәтләр атамасы)

иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатына туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта.

Күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү критерийларына туры килми, түбәндәге нигезләр буенча:

____

____

(критерийларга туры килмәү очраклары күрсәтелә)

Татарстан Республикасы
Премьер министры урынбасары

Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмә) кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты

Вазыйфа	Телефон	Электрон адрес
Рәис	(843) 222-90-20	tourism.rt@tatar.ru
Рәис урынбасары	(843) 222-90-22	Ekaterina.Barabanova@tatar.ru
Туристлык индустриясен үстерү бүлеге җитәкчесе	(843) 222-90-40	Anastasia.Sofina@tatar.ru

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

Адресы	Вазыйфа	Телефон	Электрон адрес
420014, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1	Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе җитәкчесе	+7 (843) 264-77-84	Guzel.Shakirova@tatar.ru